**Иң зур байлык - тәрбияле бала**

# *Самар шәһәр татар милли-мәдәни мохтариятенә - 10 ел!*



Денисләләр иң зур бүләкләрен Рифкат Хуҗинга тапшырдылар

Чирек гасырлык тарихы булган “Туган тел” җәмгыяте үз җилкәсендә барлык бәйрәмнәрне дә күтәреп барды. Алар түбәндәгеләр: Нәүрүз, Сабан туе, Сөмбелә, балалар фестивале. “Туган тел” җәмгыяте кысаларында ир-егетләребез тәҗрибә туплап, үз ояларын кора башладылар. Шулай итеп, өр-яңа татар оешмалары барлыкка килде. Шуларның берсе - Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мохтарияте. Бу оешмага быел ун ел тула.

Җәмгыятьнең беренче юбилее. Аның җитәкчесе булып күп еллар буена Әхмәдулла углы Җәмил абый Вәлиуллин эшләде. Ул үз тирәсенә татарның асыл егетләрен туплый алды. Барчасы да эшмәкәр, барчасы да булдыклы, барчасы да олпат ирләр. Җәмил абый лаеклы ялга киткәч, үз урынына Рифкат әфәнде Хуҗинны тәкъдим итте. Һәм исәп-хисап - сайлау җыелышында Рифкат Хуҗин кандидатурасы каршылыксыз гына рәислеккә узды. Тормышта шулай. Яңа рәис яңа директорны үзе куя. Рифкат әфәнде Хуҗин урынбасары итеп зур укымышлы, инсафлы, битенә кызыллык китерми торган Илдар Тренгуловны алды.

Бер “Туган тел” мөстәкыйль биш оешмага әйләнде. Җәмгыять “балалагач”, вазыйфалар да бүленде. Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мохтариятенә “Балалар фестивале” һәм “Сөмбелә” бәйрәмнәре рухи мирас булып күчтеләр.

“Балалар фестивале”н оештыруда үзенчәлекләре шунда ки, жанр дигән нәрсәгә зур игътибар итәсең. Бу нарасыйларның дөньяны кабул итүләренә бәйләнгән. Бала-чага төрлелекне ярата.

Ни өчен моңа җентекләп тукталдым соң?

Рифкат Хуҗин мохтарият җитәкчесе буларак, менә шул психологияне яхшы аңлап эш итә. Самар балалар бәйрәменә һәр елны яңа коллективлар килә. География татар авыллары белән генә чикләнми. Татар теле предмет булып кермәгән мәктәпләрдән дә балалар чакырыла. Шул ук вакытта үзешчән коллективларга программа туплауда тулы ирекле бирелә. Бертуктаусыз шәһәрләр күтәрелә. Самар, Тольятти, Сызран, Подбельск. Көн тәртибендә Яңа Куйбышев һәм Җигүле шәһәрләре тора.

Балаларны җыеп, тамаша куйдыру үзе бер олуг мәшәкать булса, әле бит аларга үрнәк тә күрсәтергә кирәк. Һәр балалар фестиваленә рухи мәркәзебез Казаннан нинди генә амплуадагы артистлар чакырылмый! Татар халкының үзәк өзгеч җырларын башкаручы Фердинанд Сәлахов, эстрадабызның иң-иң чибәр йөзле һәм сәләт иясе Рөстәм Асаев, сәгатьләр буена фортепианога кушылып Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин, Мансур Мозаффаров, Александр Ключарев, Сара Садыкова, башка классик композиторларның әсәрләрен башкаручы Илүсә Хуҗина һәм башкалар һәм башкалар.

Бу да мохтарият җитәкчесе Туктаргали углы Рифкат әфәнде Хуҗинның рухи офыгы. Аның музыканы аңлый белүе. Артистларны сайлый белүе. Самарда торып, Казан премьераларына чабучы ир ул! Казанда торучыларга караганда Казан концертларын Рифкат абый күбрәк карый. Тик аермасы бар. Теләсә кемне карарга бармый. Татар концертларындагы билдән түбән шаяруларны бөтенләй кабул итми. Театрлардан Камал театрына гына мөкиббән.

Аңлый белү, ярата белү була. Ләкин дә бит әле һәрнәрсәгә акча дигән нәрсә кирәк! Балаларны, артистларны, кунакларны ашату дигән нәрсә бар.

Буыннар чылбырын өзмәс өчен, буыннан-буынга әхлаки бизмәннәр күчеп барсын өчен, бәйрәм сәхнәсенә ветеран укытучылар күтәреләә, аларга Рифкат Хуҗин бүләкләр тапшыра.

Рифкат абый - Самарда беренче булып татар бәйрәмнәрен баннерларга күтәргән кеше! Бу бәйрәмгә генә түгел, татарга зур реклама! Самарда өч дистә төрле милләттәге оешмалар тамаша куя, ләкин дә баннерларда тик татар бәйрәмнәре генә.

Ә аларның хакы биленңне сындырырлык. Барчасын бергә кушсаң, барлык чыгымнарны исәпкә алгач, һәр уздырган Балалар фестиваленә Рифкат Хуҗин 400 мең сум акчасын чыгарып куя. Моны сирәкләр эшли ала.

Тамашачылар залга килгәч, әзерне генә күрәләр. Ә ул әзерне Рифкат Хуҗин җитәкләгән команда өч ай әзерли.

Рифкат Хуҗин белән эшләү читенме?

Читен. Чөнки ул бик таләпчән. Тик ул таләпчәнлек бүгенге мөмкинлекләрдән чыгып әйтелә. Шул ук вакытта җиңел. Чөнки ул киңәшеп эшли һәм үзенең дәрәҗәсе белән башкаларны изми. Кыска җөмләләр белән сөйли. Тик менә шул кыскалыкта роман фикере ята.

Ул, җитәкче буларак, таләпләрен тулысынча куя. Шул ук вакытта, эш уңышлы килеп чыксын өчен, мин дә, бәйрәмнәрне алып баручы буларак, аңа теләкләремне җиткезәм. Финанс ягыннан нинди генә авырлыклар чыкмасын, җидегә ярылса да, Рифкат абый акчаны таба. Аның каты ачуланганын ишетмәссең. Шул ук вакытта егылып мактаганын да күрмәссең. Бу сыйфатларны мин аның кимчелеге йәисә өстенлеге, дип тә әйтә алмыйм. Ул - аның яшәеше. Хезмәттә кайнап яшәгән ирләрнең күбесе

**Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мохтарияте мөдире Илдар Тренгулов фикере:**

“Рифкат абый Хуҗин белән беренче мәртәбә мин 2010 елда очраштым. Һәм бер фикергә килдем. Биргән сорауларга ашыгып җавап кайтармас. Төптән уйлап әйтер. Юл бирә белә. Шул ук вакытта дөреслектән тайпылмый. Хуҗин әфәндегә урынбасар итеп мине Шамил абзый Баһаутдин тәкъдим итте. Шунда мин аңладым. Рифкат абыйның олылар фикеренә колак сала белгәнен.

Рифкат абый татар егетләренә үз фирмасында эш тә табып бирә. Хәзерге вакытта бу бик мөһим нәрсә. Аның: “Кешегә балык бирергә кирәкми, кармак бирергә кирәк”, дигәне күңелгә уелып калган. Егетләр һәм кызлар белән җиңел аралаша. Үзе хак булса, юлны бирмәс. Чын татар ире!”

**Татар милли хәрәкәте ветераны Сәлеметдин углы Шамил Баһаутдин фикере:**

“Ир-егетләрне бәяләгәндә мин аларның әти-әниләренә булган мөнәсәбәтләренә игътибар итәм. Балаларына хуҗа була беләме? Динебез Ислам таләпләренә мөнәсәбәте ничек? Ирләр Рифкат Хуҗиндай әти-әниләрен яратсалар, бәхетсез картлар булмас иде. Рифкаттәй әнисен хөрмәтләгән ирләр күбрәк булсын тормышыбызда.



Тупли авылы балалары чыгыш ясый

шундый кебек тоела миңа. Алар икенче орбитада һәм һәрнәрсәне икенче бизмән белән үлчиләр. Милли хәрәкәттә шау ирләр. Берсеннән-берсе асыл ирләр. Барчасы да татар милләте өчен янып яшиләр. Шулар исемлегендә Туктаргали углы Рифкат Хуҗин.

Мин - Шамил кызы Наилә Сабирҗанова, 25 ел буена татар милли хәрәкәтендә кайнаган кеше буларак, Рифкат Хуҗин турындагы фикерләремне җиткездем. Ә хәзер Сезгә аның турында үз фикерләрен аның белән эшләгән ирләр әйтәләр.

Атаның баласын яратуы - аның әйбер алып бирүендә генә түгел. Аның кырыс таләпчәнлегендә. Баласының бәхете турында уйлаган ата балага таләпчән. Хуҗин шундый. Гомереңне тыныч яшисең килсә, балаларны динебез Ислам таләпләре буенча тәрбияләргә кирәк. Рифкат Хуҗин Коръән таләпләренә береккән, дип әйтә алам. Ул үз өендә - президент. Һәм, әйтергә кирәк, яхшы президент. Гаиләсендә башлык булган ирнең хезмәтендә дә үрнәк алырлык. Рифкат Хуҗин шундыйлардан.”

**Наилә САБИРҖАНОВА.**

**Тәрбия**

## Балаларыгызны еш үбегез

Пәйгамбәребез Мостафа (с.г.в.) әйткән:

«Балаларыгызны еш үбегез. Чөнки һәр үбү өчен җәннәттәге дәрәҗәгез бер баскычка күтәрелер. Фәрештәләр үбүләрегезне санап, гамәл дәфтәрегезгә савап язарлар».

* * *

## Фикер

«Безгә изге гамәлләр кылырга, изге гамәл кылучыларны күрә белергә, аларны күрсәтә дә белергә кирәк».

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ.**

